РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 185

Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре алып бару исемлеге һәм муниципаль контрольнең нәтиҗәлелек күрсәткечләрен бәяләү тәртибен раслау турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы, 2008 елның 16 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.04.2019 чыккан 324 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның яшәеш сыйфатын бәяләү индикаторлары һәм 2018ел йомгаклары буенча алар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге башкарма дисциплинасы халәте турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Кушымта итеп бирелә торган Кайбыч муниципаль районы территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен расларга (Кушымта №1).
2. Муниципаль контрольнең нәтиҗәлелек һәм эффективлык күрсәткечләрен расларга (Кушымта №2).
3. Әлеге Карарны Интернет челтәренең мәгълүматый-телекоммуникацион «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Н.Макаровка йөкләргә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советының
23.09.2019 185 номерлы карарына
Кушымта №1

**Кайбыч муниципаль районы территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе**

1. Әлеге Тәртип муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә аларны башкаруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары процедурасын билгели.

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеге түбәндәге системалаштырылган мәгълүматлар исемлеген тәшкил итә:

а) муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла торган муниципаль контроль төрләре турында;

б) муниципаль берәмлек территориясендә тиешле муниципаль контрольне башкаруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары атамалары турында;

в) тиешле муниципаль контроль төрләрен көйләүче Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге норматив хокукый актларының реквизитлары.

3. Исемлекне формалаштыру һәм алып баруны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

4. Исемлекне раслау, исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү, исемлектән мәгълүматларны төшереп калдыру Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5. Исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү я булмаса мәгълүматларны төшереп калдыруга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарын контрольне башкаруга вәкаләтләр билгеләүче норматив хокукый актлар кабул итү нигез булып тора.

6. Исемлек түбәндә бирелгән форма буенча алып барыла. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны башкаруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге формасы

| № п/п | «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләре атамалары | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә башкарыла торган муниципаль контроль төрләрен башкаруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары атамалары | Тиешле муниципаль контроль төрләрен көйләүче Россия Федерациясе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге, җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль җир контроле | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре Палатасы | Башкарма комитетның 29.03.2019 чыккан 151 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү административ регламентын раслау турында» карары; Советның 22.04.2019 чыккан 160 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле Нигезләмәсен раслау турында» |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 23.09.2019 185
номерлы карарына Кушымта №2

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге**

| № п/п | Күрсәткечләр | Исәпләү методикасы | |
|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль контрольне узган елга караганда гамәлгә ашырганда профилактик чаралар санының үсеше, %. | Еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %**, монда<br>A- агымдагы елда үткәрелгән профилактик чаралар саны;<br>B – узган елда үткәрелгән профилактик чаралар саны. |
| 2 | Төзекләндерү кагыйдәләрен бозган очракта юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү фактларының кимүе, %; | Еллык күрсәткеч | **V = (A / B- A1 / B1) x 100 %,** монда<br>A- узган ел төзекләндерү муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны бербөтен (административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.6 маддәсе);<br>A1 – агымдагы елда төзекләндерү муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны бербөтен (6 административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 6 нчы пункты);<br>B – узган ел үткәрелгән планлы рейдлар саны (системалы мониторинг) бер.;<br>B1 – агымдагы елда үткәрелгән рейдлар саны (Системалы мониторинг) бер.. |
| 3 | Муниципаль районда аларны гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, (шәһәр округында) контроль төрләренең гомуми санынннан,%. | Еллык күрсәткеч | **V = A / B x 100 %,** монда<br>A- – муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча кабул ителгән административ регламентлар саны;<br>B - муниципаль контрольнең расланган төрләре. |